# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **23.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Уразай авыл җирлегенә
керүче Уразай авылында 2020 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дурт йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Уразай авылынын Речная хэм Подгорная урамнарында асфальт түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау ;
- Уразай авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру;
- Уразай авыл территориясен җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Уразай авыл халкынын ялын оештыру, бэйрэмнэр үткәрү(Җиңү бәйрәме,сабантуй, балаларны яклау көне,халыкара өлкәннәр көне),
- Уразай авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Уразай авылында юлларны кардан чистарту;
- Уразай авылында җәй көне территорияне чабу;
- Уразай авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен ремонтлау;
- Уразай авылында коры агачларны, куакларны кисү, гербицид белән тоташ химик эшкәртү уткэру;
- Уразай авылында ике телдә урам күрсәткечләре әзерләү һәм урнаштыру;
- Башкарма комитет ихтыяҗлары өчен генератор сатып алу;
- Уразай авылының Энгельс урамы ,Садовая урамы буенча юлларга вак таш җәю;
- балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Энгельс ур., 65 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уразай авыл жирлеге башлыгы: Шэрифуллина А.М.